**КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИУТЫ
*Гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы*

Р.Р.Сәлахова

# СӘНГАТЬ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ

Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы

Казан – 2017

**Сәлахова Р.Р.**

**Сәнгать өлкәсендә татар теле:** Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы (2 кисәк) / Р.Р. Сәлахова. – Казан, 2017. – 56 б.

*Фәнни мөхәррир* –
Р.Р.Җамалетдинов, филология фәннәре докторы, профессор

*Рецензентлар:*
филология фәннәре кандидаты, доцент Л.М. Гиниятуллина
филология фәннәре кандидаты, доцент Г.Ф. Зиннәтуллина

Кулланма югары уку йортларының сәнгать бүлегендә белем алучы студентларга юнәлдерелгән. Хезмәттәге һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмияткә ия булган текстлар һөнәри компетенцияне формалаштыру максатын күздә тотып тәкъдим ителде. Беренче кисәктә сынлы сәнгать турындагы текстлар урын алды һәм ул “Дизайн” белгечлеген үзләштерүче студентларга тәкъдим ителде. Кулланманың икенче кисәге “Музыка”белгечлеге буенча белем алучы студентларга атап язылды.

Лев Толстой исемендәге
филология һәм мәдәниятара багланышлар
институты укыту методик советы
(9 нчы номерлы беркетмә, 3 нче июль, 2017 нче ел)

© Казан федераль университеты, 2017
© Сәлахова Р.Р., 2017

# КЕРЕШ

Һөнәри белем бирә торган югары уку йортларында “Татар телендә һөнәри багланышлар” (“Татарский язык в профессиональной коммуникации») фәне студентларның татар телендә үз һөнәренә бәйле булган барлык мәгълүматны тиешле дәрәҗәдә аңлый һәм аңлата белүенә, һөнәр үзләштерү юлында аннан иҗади файдалана алуына корылган.

Аралашу ихтыяҗы булдыру, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни мәгълүмат туплау өчен, “Татар телендә һөнәри багланышлар” дәресләрендә кулланылган иң уңышлы алымнарның берсе – текстлар белән эш. Текст эчтәлегенең студент сайлаган һөнәр белән бәйле булуы бик мөһим, чөнки студент югары һөнәри белем бирү уку йортына билгеле бер һөнәр үзләштерү өчен укырга керә һәм булачак һөнәре белән бәйле теләсә нинди мәгълүмат анда кызыксыну уятырга сәләтле. “Музыка” белгечлеген үзләштерүче студентларга атап төзелгән әлеге кулланмада, мәсәлән, татар музыка сәнгате тарихы, милли музыка уен кораллары һәм башка шундый музыка сәнгатен яктырткан текстлар бирелде. Һәр текст ахырында биремнәр һәм контроль сораулар тәкъдим ителде. Биредә студентка тексттагы иң әһәмиятле мәгълүматны сайлап ала белү, тектның эчтәлегеннән чыгып, аңа исем уйлап табу, текстны тулыландыру, яки тексттагы терминнарга билгеләмә бирү, текст буенча сораулар әзерләү яки, киресенчә, җавап бирү һ.б.ш. биремнәр һәм күнегүләр тәкъдим ителә. Алар арасында тексттагы аерым фактларны конкретлаштыру, аларга бәя бирү, тексттагы фактлар белән килешү яки килешмәвеңне белдерү кебек текст эчендәге мәгълүматны сөйләмдә уңышлы куллана алуга корылганнары да бар.

Гомумән алганда, әлеге биремнәр һөнәри сөйләм күнекмәләрен формалаштыруга, сөйләмне, төгәлрәге, һөнәри сөйләмне камилләштерүгә юнәлдерелгәннәр. Теге яки бу текстка яки аның эчтәлегендәге аерым бер фактка нигезләнеп, тексттагы сөйләм берәмлекләрен уңышлы кулланып, студент үзенең фикерен белдерә ала икән, димәк, һөнәри сөйләм биреме үтәлде дигән сүз.

Һөнәри белем алучы студентлар үзләштерә торган белгечлекләре белән бәйле булган төп терминнарны да яхшы белергә тиеш. Аерым бер өлкәне чагылдырган текстларда шул өлкә белән бәйле терминнарның күп булуы гаҗәп түгел. Сәнгать өлкәсенә караган текстларда, мәсәлән, иң әһәмиятле тел берәмлекләре булып сәнгать терминнары тора. Студент тексттан үз белгечлеге белән бәйле терминнарны табып, аларга татар телендә билгеләмә бирә белергә, аларның мәгънәләрен аңлап эш итәргә тиеш. Терминнарның татарча-русча атамаларын өйрәнүгә дә зур игътибар сорала. Булачак һөнәре өлкәсендәге күпсанлы терминнарның ике телдә яңгырашын өйрәнү студентларга фәнни планда гына түгел, гомумән, дөньяны танып белү юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк. Кулланмада тәкъдим ителгән музыка терминнары сүзлекчәсе шул максатны күздә тотып бирелде.

БЕРЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МУЗЫКА СӘНГАТЕ

1. Татар музыка сәнгате тарихы.
2. 19-20 йөзләрдә татар музыка сәнгате.
3. Татар милли музыка сәнгатенә нигез салучы шәхесләр

Татар музыка сәнгатенең чыганагы төрки каганатлар дәверенә барып тоташа. Ул Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы һ.б. төрки-татар дәүләтләрендә төрле *рухани* һәм *дөньяви* формаларда, *профессиональ* һәм *үзешчән* җырчылар, музыка уен коралларында башкаручылар иҗатында чагыла. Татар музыка сәнгате мәҗүсилек заманы һәм ислам дине йолаларын үткәргәндә башкарылган музыка, мәдхия, мемориаль жанрларда, сарай музыкасы традицияләрендә, хәрби йола бәйрәмнәре, сарай һәм халык бәйрәмнәрендә күңел ачу рәвешендәге музыкаль-поэтик формаларда үсә. Татар халкының традицион музыка кораллары булып кубыз, курай, гөслә, давылбаз, думбра, дәф һ.б. санала. Аларның кайберләре халык осталары кулы белән ясала, икенчеләре гарәплән үзләштерелгән классик мөселман музыка уен кораллары була.

Татар милли көйләренә ангемитоника хас; традицион буларак ул җырлар фәкать бер тавыш өчен чыгарыла. 16 йөз уртасыннан татар халкының музыка сәнгате көчен-кодрәтен югалта: элек иҗтимагый әһәмияткә ия булган формаларның кирәге калмый, бу хәл жанр һәм стильләрнең акрынлап чикләнүенә китерә. Шул сәбәпле татар халкының милли музыкасы 20 йөз башына кадәр ялгыз башкаручылар иҗатындагы фольклор җырлары буларак кына сакланып кала.

18 йөздә, уку йортлары программасына уен коралларын үзләштерү дәресләре кертелү нәтиҗәсендә, төбәктә рус музыкасының беренче учаклары барлыкка килә. 19 йөз ахырына Казанда профессиональ музыка белем бирүнең нигезләре салына. Төрле елларда К.Эйзрах, Л.К.Новицкий, А.А.Орлов-Соколовский, Р.А.Гуммертларның хосусый музыка мәктәпләре эшли башлый. Казан музыка училищесе дә Гуммерт мәктәбе нигезендә оеша.

**БИРЕМНӘР**

1. Тексттан [w] авазы булган сүзләрне һәм **ъ, ь** билгеләре кергән сүзләрне табып языгыз, орфографиясен аңлатыгыз.
2. Текстта курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

## 19-20 йөзләрдә татар музыка сәнгате

19 йөз ахыры - 20 йөз башында Казан музыка сөючеләр түгәрәге, Нәфис сәнгать сөючеләрнең Казан җәмгыяте, Халык университетлары Казан җәмгыяте татар милли музыкасының беренче концертларын оештыра. Казанда атаклы артист һәм музыкантлар И.Гофман, С.Рахманинов, А.Скрябин, А.Гольденвейзер, К.Игумнов, Л.Ауэр, Б.Губерман, Я.Кубелик, Е.Цимбалист, Н.Фигнер, Л.Собинов, А.Нежданова концертлар бирә; "Зиминның Мәскәү операсы артистлары ширкәте", С.-Петербургтан М.И.Петипаның балет труппасы, Мәскәүдәге Зур театрның Е.В.Гельцер җитәкчелегендәге балет труппасы һ.б. гастрольгә килеп чыгышлар ясый. Казандагы опера театры М.Мусоргский, П.Чайковский, А.Рубинштейн, А.Даргомыжский кебек рус авторларының, Ж.Бизе, Р.Леонкавалло, Дж.Верди һ.б. чит ил композиторларының

әсәрләреннән бай репертуар үзләштерә. Ф.И.Шаляпинның артистлык карьерасы Казанда башланып китә.

19 йөз ахыры - 20 йөз башында халык көйләре нигезендә, рус һәм Европа классик музыкасы казанышларына таянып, хәзерге профессиональ татар милли музыка сәнгате формалаша. Музыкантлардан З.Яруллин, Ф.Туишев, Х.Хәйбулкин ("Хәйбулкин маршы" авторы), җырчылардан К.Мотыйги, Ф.Латыйпов, М.Искәндәрева һ.б.ның эшчәнлеге шул елларда башлана.

20 йөзнең 20-30 нчы елларыннан татар музыка сәнгате композиторлар иҗат иткән үзенчәлекле төрле жанр әсәрләре белән байый: гыйльми нигездә милли музыканың мәгариф системасы булдырыла. Татарстанда композиторлар иҗатының формалашуына татар драма труппалары сәхнәгә куйган музыкаль драма әсәрләренең дә тәэсире зур була. Татар композиторлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе С.Сәйдәшев иҗаты татар музыкаль театры формалашуы белән тыгыз бәйләнгән. Ул спектакльләрнең музыка бизәлешен үзгәртә, милли музыканы сәхнәдәге вакыйгаларга бәйләве белән музыкаль драма жанрын нигезли. Милли музыканың тарихи тәҗрибәсен оста файдаланып, Сәйдәшев яңа интонацияләр һәм ритмнар, күптавышлылыкның гармониялелеген, оркестр яңгырашының тембр төрлелеген баета, милли татар симфонизмына нигез сала. Аның "Зәңгәр шәл", "Наёмщик", "Кандыр буе" музыкаль драмалары һәм 1920-30 еллардагы музыка-сәхнә әсәрләре милли музыканың төрле жанрлары үсеше өчен үрнәк була.

Татар музыка сәнгатенең формалашуына С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдев, В.Виноградовларның "Сания" (1925), "Эшче" (1930) беренче татар опералары зур йогынты ясый. Татар опера студиясендә (1934-38) музыка өлкәсендә милли кадрлар әзерләү Татар опера һәм балет театрын оештыруга юл ача. Музыка театрның үсешенә З.Бәйрашева,

М.Булатова, А.Измайлова, Г.Кайбицкая, М.Рахманкулова, У.Әлмиев, Н.Даутов, Ф.Насретдинев, Р.Билалова, Г.Сәйфуллина, З.Хисмәтуллина, В.Шәрипева, А.Аббасов, Л.Верниковский, Ю.Борисенко, З.Сөнгатуллина, Х.Бигичев, В.Ганиева, Г.Ластовка, Р.Сәхәбиев, Е.Михайлова кебек әйдәп баручы опера җырчылары һәм А.Гацулина, Б.Әхтәмев, Н.Юлтыева, Ә.Нарыков, Г.Калашникова, Р.Садыйков, И.Хәкимева, С.Хантимерева кебек балет солистлары зур өлеш кертәләр.

Радиотапшырулар оештырылуы (1927), Татар филармониясе, Халык иҗаты йорты (1939), Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуы Татарстандагы музкаль-иҗтимагый тормышны җанландырып җибәрә. 1939 елда ТАССР Композиторлар берлеге оештырыла. 1945 елда Казан консерваториясе ачыла.

**БИРЕМНӘР**

1. Текстны укыгыз, эчтәлеге буенча биш сорау әзерләгез.
2. Түбәндәге музыка белгечләренең берсе турында тулырак мәгълүмат туплап, сөйләргә әзерләнеп килегез: И.Гофман, С.Рахманинов, А.Скрябин, А.Гольденвейзер, К.Игумнов, Л.Ауэр, Б.Губерман, Я.Кубелик, Е.Цимбалист, Н.Фигнер, Л.Собинов, А.Нежданова
3.Тесттагы бер дөрес җавапны билгеләгез:

1. Казан музыка училищесы кем мәктәбе нигезендә оеша?

а) К.Эйзрах;
ә) Л.К.Новицкий;
б) Р.А.Гуммерт.

2. Кайсы артистның артистлык карьерасы Казанда башланып китә?

а)Шаляпин;
ә) Чайковский;

б) Мусоргский.
3. Татар милли көйләренә кайсысы хас?
а) гемитоника;
ә)ангемитоника;
б)диатоника.
4 Спектакльләрнең музыкаль бизәлешен үзгәртүче, музыкаль драма жанрына нигез салучы композитор.
а)Н.Җиһанов;
ә)С.Сәйдәшев;
б) Ф.Яруллин.
5. Кайсы музыка уен корал татар халкыныкы түгел?
а)кубыз;
ә)балалайка;
б) курай.

**Татар милли музыка сәнгатенә нигез салучы шәхесләр**

1930 еллар ахырыннан әсәрләре милли музыка классикасы фондында лаеклы урын алган күренекле татар композиторларының иҗади эшчәнлеге башлана. Музыкаль театр өлкәсендәге казанышлар аеруча игътибарга лаек: Н.Җиһановның "Алтынчәч", "Җәлил", М.Мозаффаровның "Галиябану" опералары, Ф.Яруллинның "Шүрәле" балеты, Җ.Фәйзинең "Башмагым" муз. комедиясе иҗат ителә; Н.Җиһановның "Кырлай" симф. поэмасы һәм "Татар халык көйләренә сюита"сы, А.Ключарёвның "Идел симфониясе", З.Хәбибуллинның скрипка өчен әсәрләре кебек симфония, камера-инструменталь, җыр (вокал) музыкасы жанрлары үзләштерелә. Алардан соң килгән буын композиторларның аеруча күренекле вәкиле - Р.Яхин. Ул беренче татар фортепиано концерты, күпсанлы романс, җыр һәм фортепиано әсәрләре иҗат итә. Опера, балет, симфония һәм камера-инструменталь музыка әсәрләре өлкәсендә зур көч куйган композиторлар: А.Монасыйпов ("Муса Җәлил"

симфония-поэмасы, "Тукай ритмнары" җыр һәм симф. поэмасы), Ә.Бакиров ("Су анасы" балеты), Х.Вәлиуллин ("Самат" операсы), И.Шәмсетдинев, А.Леман, А.Вәлиуллин һ.б. 1960-70 һәм аннан соңгы елларда татар композиторларының иҗат даирәсе киңәя төшә. Ф.Әхмәтев, Р.Билалов, Р.Еникиев, Б.Мөлекев, И.Якупов, М.Яруллиннар яңа стилистиканы булдыруга һәм фольклор чыганакларын заманча проф. техник чаралар б-н бәйләп үстерүгә зур өлеш кертәләр. 1980-90 елларда Татарстанда Р.Кәлимуллин, Л.Хәйретдинева, Р.Әхиярова, М.Шәмсетдинева, Ш.Шәрифуллин һ.б. композиторлар уңышлы иҗат итәләр. Бүгенге көндә Татарстан композиторлары иҗатында камера-инструменталь һәм вокаль музыка төп урынны алып тора.

Милли музыкада композиторларның беренче җырлары 1910 елларда яңгырый (Ф.Латыйпов, С.Габәши). Җыр жанрына аеруча игътибар итү С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Ж.Фәйзи, Н.Җиһанов, З.Хәбибуллин, А.Ключарёв, Р.Яхин, Ә.Бакиров һ.б. композиторларга хас. С.Садыйкова, Л.Батыр-Болгари иҗатында җыр төп урынны алып тора. Ш.у. Ш.Мәҗитев, Ә.Хәйретдинев, З.Гыйбадуллин, М.Макаров, И.Хисамов, Ф.Әхмәдиев һ.б. һәвәскәр композиторларның җырларын да халык яратып тыңлый һәм башкара. һәвәскәрләрнең үзләре иҗат итеп, әсәрләрен үзләре үк башкаруы аеруча киң җәелә.

Татар милли җыр сәнгатендә Г.Сөләйманова, Р.Ваһапов, З.Басыйрова, Ә.Афзалова, И.Шакиров, Х.Бигичев, Г.Рәхимкулов, Р.Ильясов, Ш.Әхмәтҗанов, Р.Ибраһимова, В.Гыйззәтуллина, А.Туишева, Ф.Сөләйманова, Н.Василова, З.Сәхәбиева, Р.Ибраһимов, Гөлзадә, А.Фәйзерахманов, М.Сөнгатуллин, Р.Харисовлар татар башкару сәнгатенең югары зәвыкле осталары булып танылa. Татар композиторларының әсәрләре чит илләрдә дә танылa. Татар музыкасы халыкара фестивальләрдә

башкарыла, композиторлар конкурсларында билгеләп үтелә. Казанда Европа-Азия хәзерге заман музыкасы фестивальләре, Федор Шаляпин исемендәге опера фестивале, Рудольф Нуриев. исемендәге классик балет фестивале үткәрелә. Татарстан Республикасының Дәүләт симфония оркестры, Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры, Татарстанның Дәүләт кыллы квартеты киң танылган башкаручы коллективлар булып санала. Республикада музыка коралларында ялгыз башкару гаять нык үсеп китә: Р.Абдуллин (орган), М.Әхмәтев (скрипка), Л.Маслова (виолончель), Э.Әхмәтева, Ф.Хәсәнева (фортепиано) һ.б.

**БИРЕМНӘР**

1. Җөмләләрдәге сүзләрне тиешле тәртипкә куеп дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.

*С.Габәши татар формалашуына, Г.Әлмөхәммәдев, татар "Сания" (1925), "Эшче" (1930) беренче музыка опералары ясый сәнгатенең зур В.Виноградовларның йогынты.*
*Әсәрләре Р.Яхин беренче фортепиано концерты татар фортепиано, романс, җыр иҗат итә һәм күпсанлы.*
*Татарстан иҗатында көндә камера-инструменталь алып һәм вокаль тора бүгенге төп композиторлары урынны музыка.*
*Махсус әзерли күп кенә уку эшләп белемле музыка белгечләре йортлары торган килә: Казан мәдәният һәм сәнгать университеты, Казан федераль университетының С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе, музыка училищесе, көллиятләре, мәктәпләре һ.б.*

2. Беренче баганадагы музыкальәсәрләрнең үз авторларын икенче баганадан эзләп табып , дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.

"Алтынчәч"операсы С.Габәши

"Җәлил" операсы Н.Җиһанов
"Галиябану" операсы С.Сәйдәшев
"Шүрәле" балеты Н.Җиһанов
"Башмагым" муз. комедиясе С.Сәйдәшев
"Кырлай" симфоник поэмасы С.Габәши
"Татар халык көйләренә сюита" сы Ф.Яруллин
"Идел симфониясе" С.Сәйдәшев
“Зәңгәр шәл"музыкаль драма А.Ключарёв
"Наёмщик" музыкаль драма Җ.Фәйзи
"Кандыр буе" музыкаль драма Н.Җиһанов
"Сания" операсы М.Мозаффаров
"Эшче”операсы Н.Җиһанов

**Беренче тема буенча контроль сораулар.**

1. Татар музыка сәнгате нинди формаларда үсеш ала?
2. Татар халкының традицион музыка кораллары булып нинди уен кораллары санала?
3. Хәзерге профессиональ татар милли музыка сәнгате кайсы елларда формалаша?
4. Гыйльми нигездә милли музыканың мәгариф системасы кайчан булдырыла?
5. Кайсы татар композиторының иҗаты татар музыкаль театры формалашуы белән тыгыз бәйләнгән?
6. Татар музыка сәнгатенең формалашуына кайсы композиторларның нинди опералары йогынты ясый?
7. Татарстандагы музыкаль-иҗтимагый тормышны нинди тарихи вакыйгалар җанландырып җибәрә?
8. . К.Мотыйги, Ф.Латыйпов, М.Искәндәрева һ.б.ш.ның музыкаль эшчәнлеге ничәнче елларга туры килә?
9. 1920-30 еллардагы музыка-сәхнә әсәрләре милли музыканың төрле жанрлары үсеше өчен С.Сәйдәшевнең нинди әсәрләре үрнәк була?

10. 1980-90 елларда Татарстанда уңышлы иҗат итүче композиторлардан кемнәрне атый аласыз?

**Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият**

1. Фаткуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Татарча сөйләшик.-Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. – 312б.

2. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 1 нче кисәк. – 231 б. (300 экз.)

3. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 2 нче кисәк. – 153 б. (300 экз)

Интернет-ресурслар
www.matbugat.ru сайт татарской прессы
www.prav.tatar.ru. Портал Правительства РТ
wwwKzn.ru. Официальный портал мэрии Казани
ww.Wikipedia.ru. унивирсальная энциклопедия «Википедия»

## ИКЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

1. Курай – татар халкының милли музыка коралы.
2. Кубыз – аһәңле милли уен музыка коралы.

Татар халкының традицион музыка кораллары булып кубыз, курай, гөслә, давылбаз, думбра, дәф һ.б. санала. Аларның кайберләре халык осталары кулы белән ясала, икенчеләре гарәплләрдән үзләштерелгән классик мөселман музыка уен кораллары була.

Курай татарларда элек-электән киң таралган булган. Курайларның тавыш югарылыгы, ягъни музыкаль көйләнеш югарылыгы төрле булырга мөмкин һәм ул курайчының теләге, аның тавыш көпшәсе үлчәмнәренең (озынлыгы, юанлыгы) сайланышына бәйле. Гадәттә курайчылар коралларын үзләре ясаганнар һәм курайның озынлыгын тотам белән үлчәгәннәр. Шуннан чыгып, курайлар җиде, сигез, тугыз яисә ун тотамлы озынлыкта булалар. Курайның озынлыгы, төренә карап, төрлечә була: 120-180 мм дан адып 450-1000 мм га кадәр,

**Курай төрләре**:

•Классик курай
•Көпшә курай
•Агач курай
•Бакыр курай
•Казан курай
•Ногай курай

Татарларда курай белән кызыксыну бүгенге көнгә кадәр сүнмәгән. Татарстанда һәм татарлар яшәгән башка җирләрдә курай белән кызыксыну көннән-көн арта. Курайда татар халык көйләрен һәм хәзерге заман җырларын да башкарып була.

Татар курае, башкорт кураеннан аермалы буларак, ме
талл (гадәттә җиз)
көпшәдән ясала һәм сыбызгысыманнар төркеменә карый, баш
корт курае исә
камыштан яки кыр курасыннан ясала, сызгыртма бөкесез генә
була. Татар курае, барлык тынлы уен коралары кебек үк, күп е
ллар дәвамында гади сыбызгыдан
килеп чыккан. Ул башта ике тишекле булган, хәзер алты клапа
нлы уен коралы
формасын алган. Аның диатоник аваз рәте икедән артык октав
аны эченә ала
(икенче октавага һава агымын көчәйтү ярдәмендә күчелә). Тат
ар кураеның
тембры гаҗәеп йомшак һәм чиста. Анда башкорт кураендагы к
ебек вибрация
һәм чыҗлау авазлары бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Курайның гад
и структурасы
пентатоника чикләрендәге бик вак мелизматик бизәкләрне дә я
ңгыратуга
җайлаштырылган.

## 3. Кубыз – аһәңле милли музыка уен коралы.

Кубыз татарга башка халыклардан (кыргыз, башкорт, казах) бик күптәннән кергән булырга тиеш: әмма конструкциясе һәм фигурасы буенча татар кубызы үзенә генә хас мөстәкыйльлек алган. Барыннан да элек татар кубызының үзенчәлекле тембр төсмерен, йөртергә уңай һәм нык булуын билгеләп үтәргә кирәк. Татар кубызын ясаганда металл куллану аны көчлерәк тавышлы иткән. Әмма ул шулай да аваз чыгаручы уен коралы гына булып калган, аның зурлыгы да, аваз чыгару принциплары да көй тапшыру өчен уңайсыз. Шул сәбәпле, кубыз мелодик уен коралы булып китә алмаган. Октябрьгә кадәр ул “яшертен”,

тавышсыз уен коралы булып йөргән һәм утырмаларда, аулак өйләрдә генә уйналган, шул шартларга гына җавап биргән. Оста башкаручы кулында кубыз гадәттән тыш оригиналь яңгырый.

Үзгәрми торган төп тон фонында көйнең сизелер-сизелмәс авазлары таралганда, юу борынгы уен коралының примитивлыгы һәм камил булмавы миземли дә башлый. Хәзерге вакытта татар җыр-бию ансамбленең кызыклы һәм иҗади эшчәнлеге нәтиҗәсендә, халыкта бөтенләй югала язган курай белән кубыз Татарстанның күп кенә үзешчән коллективларында яңадан популярлык казана. Татар дәүләт филармониясе каршында халык музыка уен кораллары оркестры оештырылган. Анда кубыз белән курай үзләренә лаеклы урын алган.

## БИРЕМНӘР

1. Текстны укыгыз, әңгәмә корырга әзерләнегез.

2. Гөслә, давылбаз, думбра, дәф кебек уен кораллары турында тулы мәгълүмат туплап, сөйләргә әзерләнеп килегез.

3. Тесттагы бер дөрес җавапны билгеләгез:

1. Нинди төрле курай булмый?

а) Көпшә курай;

ә) Агач курай;

б) Таш курай.

2. Курайның диатоник аваз рәте ничә октаваны эченә ала?

а)ике;

ә) икедән артык;

б) бер.

3. Татар курае нинди чималдан ясала?

а)җиз;

ә) камыш;

б) кыр курасы.
4. Башкорт курае нинди чималдан ясала?
а)җиз;
ә) камыш;
б) бакыр.

4. Татар халык музыка уен коралларының берсе турында презентация ясагыз.

## Икенче тема буенча контроль сораулар

1. Нинди татар милли музыка уен коралларын беләсез?
2. Курайның озынлыгы нинди була?
3. Татар курае, башкорт кураеннан нинди үзенчәлеге белән аерылып тора?
4. Курайның нинди төрләре була?
5. Ни өчен кубыз мелодик уен коралы булып китә алмаган?
6. Татар кубызының нинди үзенчәлекләрен беләсез?

## Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият

1. Фаткуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Татарча сөйләшик.-Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. – 312б.
2. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 2 нче кисәк. – 153 б. (300 экз)
Интернет-ресурслар
www.matbugat.ru сайт татарской прессы
www Kzn.ru. Официальный портал мэрии Казани
ww.Wikipedia.ru. универсальная энциклопедия «Википедия»

## ӨЧЕНЧЕ ТЕМА

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе республиканың музыкаль культурасын үстерү һәм пропагандалау максатыннан чыгып 1937 елның 21 августында оештырыла. Филармония ачылу татар җырчы һәм музыкантларының башкару культурасының камилләшүенә зур этәргеч була. Филармониянең беренче коллективы - 35 музыканттан торган симфоник оркестр. Әлеге оркестрның беренче дирижеры булып М.Э. Шеппер билгеләнә, соңрак аны И.В. Аухадеев алыштыра. 1938 елның 11 гыйнварыннан ул Татар дәүләт симфоник оркестры дип атала башлый. 1939 еллар ахырында оркестр яңа ачылган Татар дәүләт опера һәм балет театр карамагына күчә.

А.С. Ключарев эшчәнлеге йогынтысында яңа коллектив - татар халык инструментлары оркестры оеша. Кызганычка каршы, 1941 елны әлеге коллектив таркатыла.1937 елны филармония каршысында татар авыз иҗаты кабинеты ачыла. Аның җитәкчесе итеп башта С.Ш. Тагиров аннан А.С. Ключарев билгеләнә. Шул ук елны филармония каршысында И.В. Грекулова җитәкчелегендә Дәүләт хор капелласы оештырыла. Ярты елдан соң капелла ТАССР җыр һәм бию ансамбленә әйләндерелә. Аның җитәкчесе һәм хорместры итеп З.С. Ахметова билгеләнә. 1991 елдан башлап әлеге бөтен дөньяга танылган ансамбль мөстәкыйль иҗади эшчәнлек алып бара башлый.

1937 елны филармониядә А.В. Казанский җитәкчелегендәге эстрада-концерт бүлеге ачыла. Татар

дәүләт филармониясе башта Киров урамында, соңрак Бутлеров урамындагы галимнәр йортында урнашкан булса, хәзер Гоголь урамындагы ике катлы бинаны били. Милли музыка үсешенә керткән зур өлеше һәм Г. Тукайның тууына 60 ел булу уңаеннан 1946 елда филармониягә бөек татар шагыйре исеме бирелә.

Филармония тарихына алтын хәрефләр белән аның сәнгать җитәкчеләренең исемнәре: Дж.Г. Садрижиганов (1948-1949), А.С. Ключарев (1950-1952), Җәүдәт Фәйзи (1953-1959), Р.К. Волков (1959-1964), А.З. Монасыпов (1966), М.Н. Нигмәтҗанов (1967-1973), И.Г. Мазитов (1975-1990) язылган. 1992 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Татар дәүләт филармониясенең җитәкчесе булып Россиянең һәм Татарстанның артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илһам Шакиров тора.

2000 елны филармониянең Павлюхин урамында урнашкан үз концерт залы барлыкка килә. Бүген филармониядә 5 коллектив эшли: Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры, Татарстан Республикасы дәүләт халык инструментлары оркестры, опера һәм камера музыкасы бүлеге, халык авыз иҗаты музыкасы ансамбле. Татар дәүләт филармониясе бөтендөнья тамашачыларын Татарстан музыка сәнгате белән таныштыру эшен алып бара. Филармония 1989 елны "Татар җыры", 2003 елны Илһам Шакиров исемендәге татар җыры башкаручылары халыкара конкурсларын оештыручыларның берсе булып тора.

Республикабызның горурлыгы булган Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе ел саен үзенең репертуарын яңарта, яңа программалар төзү өстендә эшли.

## БИРЕМНӘР

**1. Күп нокталар урынына мәгънәсенә ярашлы сүзне язысыз.**

1. Шул ук елны филармония .............И.В. Грекулова җитәкчелегендә Дәүләт хор капелласы . 2. Ярты елдан капелла ТАССР җыр һәм бию ансамбленә әйләндерелә. 3. Аның...............һәм хорместры итеп З.С. Ахметова билгеләнә. 4. 1991 елдан башлап әлеге бөтен дөньяга........................ ансамбль мөстәкыйль иҗади эшчәнлек алып бара башлый. 5. 1937 елны филармониядә А.В. Казанский ...................эстрада-концерт бүлеге ачыла.

Файдалану өчен сүзләр: *танылган, оештырыла, соң, җитәкчесе, каршысында, җитәкчелегендәге.*

***2.*Филармониядә төрле елларда җитәкчелек иткән шәхесләрнең җитәкчелек итү елларын дөрес хронологик тәртибен билгеләгез.**

а)Җ. Садриҗиһанов, Ж. Фәйзи, Р. Волкова, А. Монасыйпов, М. Нигъмәтҗанов, А. Ключарев, И. Шакиров, И. Мәҗитов;
ә)Җ. Садриҗиһанов, Ж. Фәйзи, Р. Волкова, А. Ключарев, М. Нигъмәтҗанов, А. Монасыйпов,
И. Мәҗитов, И. Шакиров;
б)Җ. Садриҗиһанов, А. Ключарев, Ж. Фәйзи, Р. Волкова, А. Монасыйпов,
М. Нигъмәтҗанов, И. Мәҗитов, И. Шакиров.

**3. Бу фактлар дөресме (“Татар дәүләт филармониясе” текстының эчтәлегенә туры киләме?)**

1. Филармония ачылу татар җырчы һәм музыкантларының башкару культурасының камилләшүенә зур этәргеч була.
Дөрес
Дөрес түгел

2. Филармониянең беренче коллективы - 45 музыканттан торган симфоник оркестр.

Дөрес

Дөрес түгел

3. 1937 елны филармония каршысында татар авыз иҗаты кабинеты ачыла.

Дөрес

Дөрес түгел

4. 2000 елны филармониянең Тукай урамында урнашкан үз концерт залы барлыкка килә.

Дөрес

Дөрес түгел

5. Республикабызның горурлыгы булган Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе үзенең репертуарын алыштырмый.

Дөрес

Дөрес түгел

**Өченче тема буенча контроль сораулар**

1. Татар дәүләт филармониясе нинди максатыннан чыгып оештырыла?
2. Филармониянең беренче коллективы дип нәрсәне атыйбыз?
3. Яңа коллектив - татар халык инструментлары оркестры кем йогынтысында оеша?
4. 1937 елны филармониядә нинди бүлек ачыла?
5. Филармониягә ни сәбәпле бөек татар шагыйре исеме бирелә?
6. Татар дәүләт филармониясенең җитәкчесе кем?

**Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият**

1. Фаткуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Татарча сөйләшик.-Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. – 312б.

## ДҮРТЕНЧЕ ТЕМА
## НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСЕМДӘГЕ КАЗАН ДӘҮЛӘТ КОНСЕРВАТОРИЯСЕ

Нәҗип Гаяз улы Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе – Казанның югары музыкаль уку йорты. Аңа 1945 елда нигез салынган. Ул Идел буе һәм Урал республикалары халыклары арасыннан югары дәрәҗәле музыкантлар ( педагоглар, башкаручылар, композиторлар, музка белгечләре) әзерләү өчен барлыкка китерелә. Консерваториянең беренче ректоры татар мәдәнияте һәм сәнгате эшлеклесе Нәҗип Җиһанов (1911-1988) була. 1990 елда консерватория нәшер итү хокукына ия була һәм фәнни, укыту һәм нота басмалары чыгара башлый. 1997 елда консерваториядә опера студиясе ачыла. Әлеге югары уку йортында 8 факультет һәм егерме кафедра бар. Шулай ук өч еллык аспирантура да бар. Консерваториядә 700 тирәсе студент һәм аспирант белем ала. Алар арасында Россиядә генә түгел, хәтта Кытай, Корея, Япония, АКШ тан килгән студентлар да күп. Әлеге уку йортында студентларның түбәндәге сәнгать коллективлары эшләп килә: симфоник оркестр, хор, опера студиясе, халык уен кораллары оркестры, «Tatarica» оркестры.

Консерватория – Халыкара, бөтенроссия, регоионара һәм республика күләмендәге фестивальләр, конкурслар, конференцияләр, семинарлар оештыра торган үзәк булп тора Мәсәлән,
«Пианофорум», «Organo Pleno» халыкара фестивальләре,
С. Сәйдәшев исемендәге җырчылар һәм татар халык уен коралларында башкаручылар конкурсы һәм башкалар.

Казан дәүләт консерваториясенең уңышлары күбесенчә педагогик коллективның югары дәрәҗәле белгечләр булуы

белән билгеләнә. Хәзерге вакытта консерваториядә И.С. Дубинина, Н.А.Фомина, Р.К.Абдуллин, В.А.Столов, Э.В.Бурнашева, М.Г.Ахметов, З.Д.Сунгатуллина, Р.А.Халитов, С.М. Хабибуллин, А.А.Фәйзуллин һ.б. музыка белгечләре укыталар. Коллективтагы 184 укытучының унысы фән докторы, утыз бере фән кандидаты һәм кырык җидесе доцент.

**БИРЕМНӘР**

**1.Тесттагы бер дөрес җавапны билгеләгез:**

1. Консерваториянең нәшер итү хокукына ия булып, фәнни,
   укыту һәм нота басмалары чыгара башлаган ел.
   а)1990 ел; ә)1995 ел; б)1991ел.
2. Консерваториядә опера студиясе кайчан ачыла?
   а)1990 ел; ә)1997 ел; б)1998ел.
3. Казан дәүләт консерваториясенә ннигез салынган ел.
   а)1948 ел; ә)1945; б)1942ел.
4. Консерватория оештырган зур мәдәни-музыкаль чараны билгеләгез.

а)«Пианофорум»; ә) «Organo Pleno» ; б) “Ягымлы яз”.

## Дүртенче тема буенча контроль сораулар

1. Казан консерваториясе нинди зур чаралар үткәрә?
2. Казан консерваториясендә ничә кафедра эшли?
3.Казан консерваториясендә якынча ничә студент белем ала?
4. Казан консерваториясендә ничә факультет бар?
5.Казан консерваториясендә якынча ничә укытучы укыта?

## Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият

1. Фаткуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Татарча сөйләшик.-Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. – 312б.

2. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 1 нче кисәк. – 231 б. (300 экз.)

3. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 2 нче кисәк. – 153 б. (300 экз)

Интернет-ресурслар

www.matbugat.ru сайт татарской прессы

www.prav.tatar.ru. Портал Правительства РТ

wwwKzn.ru. Официальный портал мэрии Казани

ww.Wikipedia.ru. унивирсальная энциклопедия «Википедия»

## БИШЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ

1937 елның декабрь аенда Татар дәүләт филармониясе каршында җыр, бию һәм музыка ансамбле барлыкка килә. Заман таләбе белән барлыкка килгән милли коллективның оештыручысы һәм аның беренче җитәкчесе җырчы Зөләйха Әхмәтова була. Алар композитор Александр Ключарев белән яңа туган ансамбльнең иҗат өслүбен, йөзен билгели.

Башлангыч чорда ансамбль алдында хор сәнгатен пропагандалау һәм халыкта аңа карата мәхәббәт уяту бурычы куела. Кыска гына вакыт эчендә коллектив бу максатка ирешә һәм тиз арада үзен Русиянең иң яхшы сәнгать коллективларыннан берсе итеп таныта.

Җырчы З.Әхмәтованың иҗади эзләнүе нәтиҗәсендә коллективның төп юнәлеше барлыкка килә – фольклорга нигезләнгән милли вокал һәм хореографиянең сәхнәләштерелгән вариантлары табыла. Ансамбль тарихында бер-бер артлы зур-зур декадалар, даими гастрольләр, бәйге-смотрлар һәм аларда җиңү шатлыклары, лауреат исемнәре алу, сәнгать турында дискуссияләр дә була. Кыскасы, ул гөрләп торган мәдәни тормыш дулкынына кушыла.

Сугыштан соңгы чорларда ансамбльнең милли коллектив буларак иҗат йөзе билгеләнә. Инде ул зур сәнгать коллективы гына түгел, ә фәнни тикшеренү үзәге булып, эксперименталь базага әверелә. Халык иҗатына төрле яклап якынаерга мөмкинлек бирелә, бу исә репертуарны милли әсәрләр белән баетуга, татар композиторлары белән иҗади аралашуга китерә. Фольклор кабинеты хорны, бию төркемен материал белән һәрдаим тәэмин итеп тора, ә

ансамбль аны сәхнәләштерә, заманча ысуллар белән, сәхнә кануннарына туры китереп, уңышлы итеп күрсәтүгә ирешә.

Зур бию остасы Фәйзи Гаскәров беренчеләрдән булып ансамбльнең бию төркеменә эчтәлекле, уйланылган сюжетлы биюләр кертә. Аның башлангычын башка хореографлар күтәреп ала, алар куйган биюләр белән берничә буын биючеләр тәрбияләнә. Ансамбль милли кадрларны үстерү буенча үзенә күрә бер лаборатория, институт, консерватория була.

Ансамбльнең сәнгать җитәкчеләре булып 1938–59 елларда - З. Әхмәтова, 1959 – 65 елларда - Җ. Айдаров, 1965–67 елларда - Ә. Абдуллин, 1939, 1967–70 елларда - А. Ключарев, 1974–78 елларда - Г. Скалозубов, 1978–2000 елларда - Л. Кустабаева, 2000 – 2005 елларда - Р. Вәлиев, 2005 елдан А. Хәмитов эшли.

Ансамбль артистларының хор һәм бию культурасы үсешендә композиторлар С. Габәши, С. Сәйдәшев, А. Ключарев, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, М. Юдин, З. Хәбибуллин, Р. Яхин, И. Хисамов, Ә. Абдуллин, Р. Гобәйдуллин, Ф. Әхмәтов, М. Шәмсетдинова, С. Садыйкова, М. Макаров, И. Якупов, Р. Мостафин, Р. Сәлимов һәм башкаларның иҗаты зур роль уйнады.

Ансамбльнең репертуарында халкыбызның күңел бизәкләрен, милли үзенчәлеген чагылдырган “Аулак өй”, “Тула өмәсендә”, “Сабан туе”, “Төрки дөнья”, “Гастрольләр меридианы буйлап”, “Корбан бәйрәме”, “Рамазан”, “Әрни әле, әрни ул яра”, “Безнең Сәйдәш”, “Былбыл Сара”, “Сарман яшьләре биюе”, “Каз өмәсе”, “Туй”, “Казан турында риваять”, “Мөһәҗирләр”, “Җиде энҗе”, “Зәңгәр шәл” (концерт варианты) һ.б. кебек бай эчтәлекле тамашалар бар.

## Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең ирешкән уңышлары

Җыр һәм бию ансамбленең *һөнәри* осталыгы һәм бу иҗат коллективының үз алдына куйган максатларының ни рәвешле гамәлгә ашырылуы сокланууга мең кат лаек. 76 ел дәвамында куелган концерт программалары Республикабыз сәнгать тарихында асылташлар кебек ялтырап тора.

Ансамбль төрле елларда Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурсларында лауреат булды. Боларга тагын Туниста узган Халыкара Карфаген фестивалендә, Франциядә узган 43 нче интернациональ фестивальдә лауреатлыкны һәм үзебезнең Габдулла Тукай премиясе белән бүләкләнүне өстәргә кирәк. Сәнгать коллективлары арасында була торган бәйгеләрдә дә безнекеләр сынатмыйлар. Җыр һәм бию ансамбле Франциядә, Испаниядә, Төркиядә, Кытайда еш кунак. Халыкара фестивальгә килгән күпсанлы иҗат төркемнәре арасында югалып калмау өчен егет-кызларның чибәрлеге, кигән киемнәренең затлылыгы гына җитми әле. Бәлки репертуарның *зәвыклы* булуы да шарт.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле төрле республикалар һәм чит илләрдә – Корея, Кытай, Монголия, Йәмән, Тунис, Италия, Мальта, Сенегал, Нигерия, Бенин, Япония, Финляндия, Германия, Югославия, Төркия, Венгрия, Англия, Гыйрак, Франция, Польша, Шотландия, Испания тамашачылары алдында уңышлы чыгышлар ясады. Чит илләрдә йөреп кайтканнан соң, коллективның репертуарына дөнья халыкларының музыкаль, вокаль-хореографик әсәрләре өстәлә килде.

Тылыңда газиз халкыңның бай мирасы торганда бу яктан борчыласы юк. Татар халкының җырлары һәм дастаннары, биюләре һәм *риваятьләре*, лирик һәм шаян йола күренешләре – барысы да ансамбльнең репертуарында. Ансамбль халыкның күңел *җәүһәрләрен* саклаучы

тылсымлы сандык ул. Шуңа күрә җыр һәм бию коллективының *һәрбер* концерты *һәрвакыт* мәдәни тормышта вакыйга итеп кабул ителә. Ул тамашачылар йөрәгендә борынгы халыкның бөек образы турында якты бер манзара тудыра.

Халыклар Дуслыгы орденлы Татарстан җыр һәм бию ансамбле коллективы узган юл үзе дә риваять кебек матур да, данлы да. Ансамбльнең иҗат тормышы, аның үткәне һәм бүгенгесе тамырлары белән татар халкының фольклор традицияләренә ялгана. Коллективның иҗат йөзе татар профессиональ сәнгате, *мәдәнияте* белән бергә формалаша. Димәк, ул ниндидер мәдәни мәркәз *вазифасын* да үтәгән. Иҗат кешеләренең күмәк
хезмәт җимеше булып ансамбльнең алтын фондында иллеләп соклангыч концерт программасы калган. Һәр халыкның тарихта тоткан урыны аның кешелек мәдәниятенә керткән өлеше һәм шул уртак *хәзинәдән* файдалана белү сәләте белән билгеләнә. Татар халкы кыска гына вакыт эчендә үз сәнгатен моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәгә күтәрә алды.

Бүгенге көндә коллективта 100 артык кеше эшли, күпчелеге махсус һөнәри белемле. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов, директор Юрий Жуков, баш хормейстер Нияз Гәрәев, Татарстанның хормейстеры халык артисты Венера Гәрәева, баш балетмейстер, Татарстанның халык артисты Раилә Гарипова, оркестр дирижеры, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин һәм артистлар бер тату гаилә булып, кулга-кул тотынышып иҗат итә.

## БИРЕМНӘР

1. Курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз һәм сүзлек диктантына әзерләнегез.

2 Текст буенча төркемдәшләрегезгә биш сорау әзерләп, әңгәмә корырга әзерләнегез.

3.Текстан тиңдәш кисәкле иң озын җөмләне табып, мәгънәсенә зыян китермәслек итеп, үзегезчә үзгәртеп языгыз.

## Бишенче тема буенча контроль сораулар

1. Татар дәүләт филармониясе каршындагы җыр, бию һәм музыка ансамбле кайчан барлыкка килә?
**2.** Татар дәүләт филармониясе каршындагы җыр, бию һәм музыка ансамбленең беренче җитәкчесе кем була?
3. Кем ул Фәйзи Гаскәрәв?
**4.** Татар дәүләт филармониясе каршындагы җыр, бию һәм музыка ансамбленең 1965–1967 нче еллардагы җитәкчесе кем була?
**5.** Татар дәүләт филармониясе каршындагы җыр, бию һәм музыка ансамблендәге 3 бию остасының фамилиясен атагыз.
**6.** Ансамбльнең башкару культурасын үстерүдә төрле елларда эшләгән хормейстерлардан кемнәрне атый аласыз?
**7.** Ансамбльнең репертуарындагы татар халкының күңел бизәкләрен, милли үзенчәлеген чагылдырган нинди әсәрләрне мисалга китерә аласыз?
**8.** Бүгенге көндә ансамбль коллективында якынча ничә кеше эшли?
**9.** Хәзерге көндә ансамбльнең җитәкчесе кем?
**10.** Татар дәүләт филармониясе каршындагы җыр, бию һәм музыка ансамбленең директорын атагыз.

**Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият**

1. Фаткуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмухаметова Э.Н. Татарча сөйләшик.-Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. – 312б.

2. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 1 нче кисәк. – 231 б. (300 экз.)

3. Харисов Ф.Ф. Татар теле: чит телле аудиториядә. 2 кисәктә. / Ф.Ф.Харисов, Г.Ф.Харисова, С.Х.Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. 2 нче кисәк. – 153 б. (300 экз)

Интернет-ресурслар

www.matbugat.ru сайт татарской прессы
www.prav.tatar.ru. Портал Правительства РТ
wwwKzn.ru. Официальный портал мэрии Казани
